Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы
Кибәк Иле авыл җирлеге Советы

Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы
Кибәк Иле авыл җирлеге Башлыгы

# КАРАРЫ

15 ноябрь, 2021 ел № 3

Питрәч муниципаль районы Кибәк Иле авыл җирлеге торак пунктларында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыеннарын билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1 һә 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 2 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы Питрәч муниципаль районы Кибәк Иле авыл җирлеге уставының 22 статьясы Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районының Кибәк Иле авыл җирлег составына керүче торак пунктларда гражданнарның үзара салым акчаларын керт һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын әзерләү һәм уздыру тәртиб турында нигезләмә, Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районының 201 елның 08 ноябрендәге 139 номерлы Кибәк Иле авыл җирлеге Советы карар нигезендә карар бирәм:

Халык җыенын ике этапта үткәрү:

- Халык җыенының беренче этабы 2021 елның 28 ноябрендә 10 сәгать ( минутта Тукай урамы, 28 нче йорт адресы буенча урнашкан авыл мәдәният йорт янында узачак. Гражданнар җыенында катнашучылар исемлегенә Яшел, Нариманов Яңа, Бакча урамнары буенча теркәлгән кешеләрне кертергә;

- Халык җыенының икенче этабы 2021 елның 28 ноябрендә 13 сәгать ( минутта Тукай урамы, 28 йорт адресы буенча урнашкан мәдәният йорты янын узачак. Гражданнар җыенында катнашучылар исемлегенә Чишмәле, Тукай, Мәкт урамнары буенча теркәлгән кешеләрне дә кертергә кирәк;

Гражданнар җыенына чыгарыла торган сорауны расларга:

«Сез, 2022 елда Кибәк Иле торак пункты территориясендә яшәү урыны буен теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 1000 сум күләмендә үзара салым кертүгә, төркем, 2 группа инвалидларны, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның т хатыннарын, көндезге уку формасы студентларын, 80 яшькә җиткән гражданнар бер тапкыр бирелә торган түләүләрдән (үзара салымнан) азат итеп һәм җир әһәмияткә ия мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны алдагы эшләрне башка өчен тотылу белән килешәсезме?:

- зират территориясен төзекләндерү

«РИЗА» «КАРШЫ».

2. Әлеге карарны «Вперед» («Алга») газетасында, Татарстан Республика хокукый мәгълүматының рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru), Питр муниципаль районының рәсми сайтында (www.pestreci.tatarstan.ru) бастыр

чыгарырга һәм  Кибәк Иле авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында игълан итәргә.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан (халыкка игълан ителгән) көненнән үз көченә керә.

Питрәч муниципаль районы
Кибәк Иле авыл җирлеге башлыгы Р.А. Сәйфетдинов